Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

# КАРАР

14 декабря 2022 ел №67

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 27декабрендәге 119 номерлы Түбән Мактама бистә Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында


Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль закон, 2022 елның 18 ноябрендәге 7 номерлы гавамик тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә («Альметьевский вестник» газетасында басма, 2022 ел, 01 декабрь, № 48)

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 27декабрендәге 119 номерлы Түбән Мактама бистә Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама ш.т.б., Гагарин ур. адресы буенча урнашкан 16:45:070120:2580 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында шәхси торак төзелешенең территориаль зонасын (Ж1), махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасын (СН3) киметергә һәм 5-8 катлы (Ж3) уртача этажлы торак төзелешенең территориаль зонасын билгеләргә;

Гамәлдәге хәл





Кертелә торган үзгәрешләр




- Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама ш.т.б., Некрасов ур. адресы буенча урнашкан 16:45:070103:741 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында рекреациянең территориаль зонасын (Р1), табигый ландшафт зонасын (Р2) киметергә һәм 8 каттан югары күпкатлы торак йортлар (Ж5) белән төзелешнең территориаль зонасын билгеләргә;

Гамәлдәге хәл




Кертелә торган үзгәрешләр




- күп функцияле иҗтимагый-эшлекле зонаның (Д1) Капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләренә, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына һәм җир кишәрлекләренең иң чик үлчәмнәренә үзгәреш кертергә: рөхсәт ителгән төзелешнең башка төрләре өчен иң зур мәйданны 5000 кв.метрдан 50000 кв.метрга үзгәртергә.

2. Әлеге карарны Түбән Мактама ш.т.б. һәм Тихоновка авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама ш.т.б. башлыгына йөкләнә.

Түбән Мактама шәһәр тибындагы
бистә башлыгы Р.А. Бадретдинов